**Азнакай муниципаль районы**
**Әлкәй авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Әлкәй авылы № 91 20 сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 31 маендагы 33 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2016 елның 27 октябрендәге 40 номерлы, 2017 елның 21 сентябрендәге 65 номерлы, 2018 елның 05 февралендәге 84 номерлы, 2019 елның 28 декабрендәге 158 номерлы, 2020 елның 10 апрелендәге 167, 2021 елның 11 октябрендәге 36 номерлы, 2023 елның 06 апрелендәге 78, номерлы карарлар редакциясендә)

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 345-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Әлкәй авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 31 маендагы №33 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы (2016 елның 27 октябрендәге 40 номерлы, 2017 елның 21 сентябрендәге 65 номерлы, 2018 елның 05 февралендәге 84 номерлы, 2019 елның 28 декабрендәге 158 номерлы, 2020 елның 10 апрелендәге 167, 2021 елның 11 октябрендәге 36 номерлы, 2023 елның 06 апрелендәге 78 номерлы карарлар редакциясендә) нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 1 пунктында:

а) алтынчы абзацта «, газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләр объектлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац белән тулыландырырга:

«- газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру

турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30.5 статьясында каралган башка шартлар;»;

в) сигезенче, тугызынчы абзацларны тугызынчы, унынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2023 елның 23 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис С.З.Зиннурова